Татарстан Республикасы Президенты
Р. Н. Миңнехановка

Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич!

Тарих институты тирәсендәге ыгы-зыгы тынып та өлгермәде, аяз көнне күк күкрәгән шикелле яңа хәбәр алдык: йөз елдан артык тарихы булган Татарстан китап нәшриятын ябарга җыеналар икән! 1919 елдан бирле эшләп килгән Татарстан китап нәшриятын юридик зат буларак гамәлдән чыгарып, “Татмедиа” акционерлык җәмгыятенә кушу – аны юкка чыгару дигән сүз инде.

“Татмедиа”, керемен арттырып, уңышлы гына эшләп килгән нәшриятның статусын үзгәртеп, аның барлык китапларын үз филиалы булган “Идел-Пресс” типографиясендә генә бастыруны максат итеп куйган. Бүген нәшрият үз китапларын тендерда җиңгән типографияләрдә эшләтә. Шушындый гади генә исәп-хисап артында бөтен Россия күләмендә үз исеме, зур тарихы булган Татарстан китап нәшриятын юкка чыгару ята.

Беренче карашка җиңел генә күренгән кушылудан нәшрият бик күп нәрсәләр югалтачак:

Кыскартулар нәтиҗәсендә югары профессиональ коллективын;

Халыкара конкурсларда, грантларда катнашу мөмкинлеген;

Дәреслекләр эшләү хокукын;

Йөз ел эчендә чыгарган продукциясенә авторлык хокукларын.

Дәүләт заказы нәшрият кеременең бер өлешен генә алып тора, “Татмедиа” акционерлык җәмгыятенә кушылу белән керемнең дәреслекләрдән, грантлардан килгән өлеше юкка чыгачак дигән сүз.

Моннан 13 ел элек оештырылып, татар матбугатын юкка чыгаруны күз уңында тоткан “Татмедиа” агентлыгы бу максатына ирешеп килә. Коллективларны пыран-заран китерү, журналистларны аз хезмәт хакына эшләтү – бу “Татмедиа” “казанышларының” бер өлеше генә. Шуларга өстәп, тагын Татарстан китап нәшриятын хәзерге статусыннан мәхрүм итү – меңьеллык тарихлы татар әдәбиятын популярлаштыра, халкыбызга ирештерә торган рухи мәркәзебезне юкка чыгару булыр иде.

Рөстәм Нургалиевич! Сездән әлеге башбаштаклыкны туктатуыгызны сорыйбыз. Татар китабы яшәргә тиеш!

Хөрмәт белән,

Марсель Галиев /[подпись]/
Татарстанның халык язучысы
Зиннур Мансуров /[подпись]/
Татарстанның халык шагыйре
Разил Вәлиев, Татарстанның халык шагыйре

Нәбирә Гыйматдинова, Татарстанның
халык язучысы
Н. Гыйматд[подпись]

Татарстан Республикасы Президенты
Р. Н. Миңнехановка

Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич!

Тарих институты тирәсендәге ыгы-зыгы тынып та өлгермәде, аяз көнне күк күкрәгән шикелле яңа хәбәр алдык: йөз елдан артык тарихы булган Татарстан китап нәшриятын ябарга җыеналар икән! 1919 елдан бирле эшләп килгән Татарстан китап нәшриятын юридик зат буларак гамәлдән чыгарып, “Татмедиа” акционерлык җәмгыятенә кушу – аны юкка чыгару дигән сүз инде.

“Татмедиа”, керемен арттырып, уңышлы гына эшләп килгән нәшриятның статусын үзгәртеп, аның барлык китапларын үз филиалы булган “Идел-Пресс” типографиясендә генә бастыруны максат итеп куйган. Бүген нәшрият үз китапларын тендерда җиңгән типографияләрдә эшләтә. Шушындый гади генә исәп-хисап артында бөтен Россия күләмендә үз исеме, зур тарихы булган Татарстан китап нәшриятын юкка чыгару ята.

Беренче карашка җиңел генә күренгән кушылудан нәшрият бик күп нәрсәләр югалтачак:

Кыскартулар нәтиҗәсендә югары профессиональ коллективын;

Халыкара конкурсларда, грантларда катнашу мөмкинлеген;

Дәреслекләр эшләү хокукын;

Йөз ел эчендә чыгарган продукциясенә авторлык хокукларын.

Дәүләт заказы нәшрият кеременең бер өлешен генә алып тора, “Татмедиа” акционерлык җәмгыятенә кушылу белән керемнең дәреслекләрдән, грантлардан килгән өлеше юкка чыгачак дигән сүз.

Моннан 13 ел элек оештырылып, татар матбугатын юкка чыгаруны күз уңында тоткан “Татмедиа” агентлыгы бу максатына ирешеп килә. Коллективларны пыран-заран китерү, журналистларны аз хезмәт хакына эшләтү – бу “Татмедиа” “казанышларының” бер өлеше генә. Шуларга өстәп, тагын Татарстан китап нәшриятын хәзерге статусыннан мәхрүм итү – меңьеллык тарихлы татар әдәбиятын популярлаштыра, халкыбызга ирештерә торган рухи мәркәзебезне юкка чыгару булыр иде.

Рөстәм Нургалиевич! Сездән әлеге башбаштаклыкны туктатуыгызны сорыйбыз. Татар китабы яшәргә тиеш!

Хөрмәт белән,

Ркаил Зәйдулла, Татарстанның халык шагыйре / Р. Зәйдулла

Газәй Рәхим, Татарстанның халык язучысы / [signature]

Р. Батулла, Татарстанның халык язучысы Р. Батулла

Рәдиф Гаташ, Татарстанның халык шагыйре, Р. Гаташ